**КАРАР**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-РӘҖӘП АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**№10** **11.06.2024 ел**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурыч түләүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Иске-Рәҗәп авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www. spasskiy.tatarstan.ru) һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http: //pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Нугаев